**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАРЫ**
**утыз дүртенче утырыш**

**«07» февраль 2024 ел** **№ 121** **Алан авылы**

**Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советының 2023 елның 25 сентябрендәге 106 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге территориясендә авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кошларын тоту кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2024 елның 17 гыйнварындагы 09/13-09/203 номерлы хатын карап, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советының 2023 елның 25 сентябрендәге 106 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге территориясендә авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кошларын тоту кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәреш кертергә, күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге территориясендә авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кошларын тоту кагыйдәләренең 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Терлек азыгын, тиресен һәм компостын туплау хайваннар йорты территориясендә генә рөхсәт ителә, анда янгынга каршы нормалар, санитария, ветеринария һәм эстетик нормалар һәм таләпләр үтәлергә тиеш.

Мөгезле эре һәм мөгезле вак терлек, һичшиксез, биркаланырга тиеш (К51 11.10.04г.п. 14. боерыгын кар. Ветеринария идарәсе).

Күзәтүчесез булган, шулай ук номеры булмаган мөгезле эре һәм вак терлек сукбай булып санала һәм кире тотылырга тиеш.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Алан авыл җирлеге башлыгы Б.Н. Хәсәнов